**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ К А Р А Р

от ______________ ПР-232 24.10.2024 № _______

«Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 маендагы ПР-67 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 маендагы ПР-67 номерлы карары белән расланган, "Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы Нигезләмә"гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. **5 бүлектә:**
5.1 пунктта «теркәлгән һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.2. Гадәттән тыш хәлләрдән һәм табигый бәла-казалардан зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү Актаныш муниципаль районы администрациясенең резерв фондыннан яшәү өчен яраклы бердәнбер торак урынны (фатир, йорт) тулысынча югалткан очракта 100000,00 сумга кадәр, яшәү өчен яраклы бердәнбер торак урынны (фатир, йорт) өлешчә югалткан очракта 50 000,00 сумга кадәр дип исәпләп чыгарыла, түбәндә тапшырылган документлар нигезендә:

**5.2 пунктының 11 пунктчасын төшереп калдырырга.**

1.2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссиясе составын, 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Ильясов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
___________ №___
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

Инфраструктур үсеш буенча Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Комиссия секретаре:

Актаныш муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык секторы мөдире (килешү буенча).

Комиссия әгъзалары:

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

• Актаныш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе;

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы;

• ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);

• ФДКУ «ТР буенча Федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 отряды» 103 янгын бүлеге башлыгы (килешү буенча);

• Актаныш районы ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе (килешү буенча);

«Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татар республика оешмасы» — «ТР инвалидлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасының Актаныш районы оешмасы рәисе(килешү буенча);

• Актаныш муниципаль районы иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча).